ГЛАВА
АЛЕКСЕЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЛЕКСЕЕВСК
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

30.04.2025 п.г.т. Алексеевское № 48

**Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладларын арттыру һәм Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 24.04.2018 ел, № 40 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренә социаль гарантияләр тәэмин итү һәм хезмәт өчен түләүне тәртипкә китерү максатларында һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттыру турында һәм «Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында»2018 елның 30 мартындагы 195 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 14.04.2025 ел, № 226 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына тәңгәл рәвештә

**карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының 24.04.2018 ел, № 40 «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» карары белән билгеләнгән тәртиптә,

2025 елның 1 маеннан бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен арттырырга.

2. Бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсе аерым оешмалары җитәкчеләренең, белгечләренең һәм хезмәткәрләренең айлык вазыйфаи окладлары күләмнәрен исәпләп чыгару өчен әлеге карарның 1 пункты нигезендә, Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү буенча Бердәм тариф челтәре кагылмый торган муниципаль берәмлекләрдә бюджет өлкәсенең аерым оешмасы структур бүлекчәсе җитәкчесе секретаренең вазыйфаи окладлары күләмен 1,1 тапкыр индексацияләргә һәм аны 15389 сум күләмендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы Башлыгының «Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләре хезмәтенә түләү буенча бердәм тариф челтәре кагылмый торган бюджет өлкәсенең аерым оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында» 24.04.2018 ел, № 40 карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

3 пунктның 3 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга.;

7 пунктның 4 пунктчасында «37 процент» сүзләрен «52 процент» сүзләренә алмаштырырга.;

4. Әлеге карарны гамәлгә ашыруга бәйле чыгымнарны финанс белән тәэмин итү тиешле финанс елына җирле бюджетларда каралган бюджет ассигнованиеләре чикләрендә гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.

5. Әлеге карар 2025 елның 1 маеннан үз көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны финанс-бюджет палатасы рәисе Е.М. Мифтаховага йөкләргә.

**Алексеевск муниципаль**
**районы башлыгы** **С.А. Демидов**